# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“19” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 19 ноябрендә «Сез 2022 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Иске Җогып авылында скважина ремонтлау (материаллар алу, торбаларын алыштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2. Иске Югуп авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү;
3. Туң җирне казу өчен бензин белән эшли торган җайланма сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 113 (бер йөз унөч) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 68 (алтмыш сигез) кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 68 (алтмыш сингез) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

   1. Иске Җогып авылында скважина ремонтлау (материаллар алу, торбаларын алыштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
   2. Иске Югуп авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү;
   3. Туң җирне казу өчен бензин белән эшли торган җайланма сатып алу

мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогыпавылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.

Совет Новошашинского сельского поселения
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы